**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чубар-Абдул авылы № 71 25 сентябрь 2017 ел

Чубар-Абдул авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре" турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары" турындагы 131номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән "Җирле референдум" турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгының 11 сентябрь 2017 елда чыккан 13 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары, Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 11 сентябрь елда чыккан 69 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары нигезләрендә,

Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Чубар-Абдул авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 19 ноябрь 2017 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   "Сез, Чубар-Абдул авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2018 елда 300 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   - Авыл эчендәге юлларны ремонтлау (Буралы авылында юлны щебенка белән каплау, Чубар-Абдул авылында юлны щебенка белән каплау);
   - Күмү урыннарын корап тоту (Мәндәй авылында зиратларның коймаларын төзәтү)

ӘЙЕ ЮК

3. Карар районның "Маяк" газетасында бастырыла, хокукый мәгълүматның рәсми порталында Татарстан Республикасы буенчаhttp://pravo.tatarstan.ru веб – адресы буенча һәм Азнакай муниципаль районынын Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: Н.А.Фатхетдинов